РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» июля 2023г. г. Альметьевск №112

Җирле салымнар суммалары елешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән яки аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булганнан соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, йә варисларның берсе дә мираска хокукка ия булмаса яки барлык варислары да варислардан читләштерелмәсә, йә мирасны берәү дә кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан, шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч еллык срок узу;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләп бетерүгә ышанычсыз дип тануның естәмә нигезләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Советының 2019 елның 25 октябрендәге 173 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.урнаштырырга.

4. Әлегә карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үз йогынтысын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов